**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 21 гыйнвар № 28

г. Казань

Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясы, «Россия Федерациясе Торак кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 29 июнендәге 176-ФЗ номерлы Федераль законның 12 статьясындагы 7 өлеш, «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтү үткәрүне оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 5 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибен расларга.
2. Россия Федерациясе Торак кодексының 180 статьясындагы 3 өлештә күрсәтелгән конкурсны үткәрү тәртибен һәм аның шартларын билгели торган Россия Федерациясе Хөкүмәте акты үз көченә кергәннән соң 90 көн узгач, әлеге карарның нигезләмәләре кулланылмый дип билгеләргә.
3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\28.docx

Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибенә 1 нче кушымта

Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларының заявкаларын һәм конкурс тәкъдимнәрен бәяләү критерийлары

1 таблица

«Тотрыклылык дәрәҗәсе» критерие буенча заявкаларны бәяләү

| Т/с | Критерий | Баллар-ның макси-маль саны | Бәяләү критерийлары | Мәгънәсе | Баллар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Тотрыклылык дәрәҗәсе | 36 | Кредит оешмасының устав капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлекләр өлеше булу | Устав капиталындагы өлеше 50%тан артык | 9 балл |
| | | | | Устав капиталындагы өлеше 25 %тан алып 50%ка кадәр | 6 балл |
| | | | | Устав капиталындагы өлеше 0 %тан алып 25%ка кадәр | 3 балл |
| | | | | Устав капиталында өлеше юк | 0 балл |
| 2. | | | Россия кредит оешма-сының Татарстан Республикасында территориаль структур бүлекчәсе булу | | 12 балл |
| 3. | | | Россия кредит оешма-сының заявканы тап-шыру көненә актуаль, халыкара агентлык-ларның берсе тара-фыннан билгеләнгән һәм бирелгән булырга тиешле финанс рейтингы булу (Moody's Investors Service, яки Standard & Poor's, яки Fitch Ratings) | Moody's Investors Service: Россия Федерациясе суверен рейтингының бер позициясеннән түбән булмаган дәрәҗә.<br>Standard & Poor's: Россия Федерациясе суверен рейтингының бер позициясеннән түбән булмаган дәрәҗә.<br>Fitch Ratings: Россия Федерациясе суверен рейтингының бер позициясеннән түбән булмаган дәрәҗә | 15 балл |

2 таблица

«Ышанычлылык дәрәҗәсе» критерие буенча заявкаларны бәяләү

| Т/с | Критерий | Баллар-ның макси-маль саны | Бәяләү критерийлары | Мәгънәсе | Баллар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Ышанычлы-лык дәрәҗәсе | 12 | Конкурсны үткәрү көненә банкның үз акчасы күләме | Үз капиталы күләме 500 млрд.сумнан артык | 12 балл |
| | | | | Үз капиталы күләме 300 млрд.сумнан алып 500 млрд.сумга кадәр | 9 балл |
| | | | | Үз капиталы күләме 100 млрд.сумнан алып 300 млрд.сумга кадәр | 6 балл |
| | | | | Үз капиталы күләме 20 млрд.сумнан алып 100 млрд.сумга кадәр | 3 балл |

3 таблица

«Хезмәт күрсәтү бәясе» критерие буенча заявкаларны бәяләү

| Т/с | Критерий | Баллар-ның макси-маль саны | Ярдәмче бәяләү критерийлары | Мәгънәсе | Баллар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Хезмәт күрсәтү бәясе | 22 | Счет/махсус счетлар ачу бәясе | Түләүсез | 5 балл |
| 2. | | | Счетка/махсус счет-ларга хезмәт күрсәтү бәясе | Түләүсез | 5 балл |
| 3. | | | Махсус счетлар һәм төбәк операторы счетлары буенча калган акча процентларын күчерү | Максималь ставка – елга 1%ка кадәр | 3 балл |
| | | | | Максималь ставка – 1 %тан алып 2%ка кадәр | 6 балл |
| | | | | Максималь ставка – 2%тан алып 3%ка кадәр | 9 балл |
| | | | | Максималь ставка – 3% һәм аннан күбрәк | 12 балл |

4 таблица

«Акча чыгымнарын контрольдә тоту һәм аларның куркынычсызлык дәрәҗәсе» критерие буенча заявкаларны бәяләү

| Т/с | Критерий | Балларның максималь саны | Бәяләү критерийлары | Мәгънәсе | Баллар саны |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | Акча чыгымнарын контрольдә тоту һәм аларның куркынычсызлык дәрәҗәсе | 30 | «Дистанцион банк хезмәте күрсәтү» системасында «Түләүләрнең күп баскычлы акцепты» хезмәте булу | - | 10 балл |
| 2. | | | Клиентка түбәндәгеләрне гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә торган бертип продукт булу (документлар белән расланган):<br>берничә баскычны куллану һәм параметрларны оператив үзгәртү мөмкинлеге белән, планлаштырылган чыгым операцияләре буенча бюджет контролен һәм үтәлешен гамәлгә ашырырга;<br>кирәк булган очракта контрольдә тотучы органнарга төбәк операторы счетлары буенча операцияләр буенча өстәмә акцепт хокукын бирү | - | 10 балл |
| 3. | | | Бертип продукт булу (документлар белән расланган) һәм, «банк-клиент» системасыннан файдаланмыйча, төбәк операторының исәпкә алу системасы һәм банк арасында автоматик мәгълүмат алышуны оештыру тәҗрибәсен гамәлгә ашыру | - | 10 балл |

Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга заявка

Күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтү фондларын формалаштыра торган төбәк операторы счетын ачу өчен Россия кредит оешмаларын конкурс нигезендә сайлап алуны үткәрү тәртибен һәм аның шартларын, шулай ук әлеге конкурс нигезендә сайлап алуга карата кулланыла торган Россия Федерациясе законнарын өйрәнеп, ______________________________________________
_________________________________________________________ нигезендә эш итүче
*(гамәлгә кую документы исеме яки ышанычнамә)*
__________________________________________________________________ йөзендә
*(вазыйфа исеме, җитәкче яки вазыйфаи затның Ф.И.Ат.и.)*
________________________________________________________________________ ,
*(кредит оешмасы исеме)*

күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең милекчеләре махсус счет ачылачак кредит оешмасын сайламаган яки бу кредит оешмасы Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 4 өлешнең 5 пунктында һәм 176 статьясындагы 2 өлештә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән очракта, күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтү фондларын формалаштыра торган төбәк операторы счетын, хуҗасы итеп төбәк операторы билгеләнгән күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау үткәрүгә акча күчерү өчен күздә тотылган махсус счет ачу шартнамәсен төзүгә конкурс нигезендә сайлап алуда катнашуга ризалыгы турында хәбәр итә.

1. Конкурс тәкъдимнәрен бәяләү өчен мәгълүмат

| Т/с | Критерий исеме | Үлчәү берәмлеге | Мәгънәсе |
|---|---|---|---|
| 1. | Кредит оешмасының устав капиталында Россия Федерация-се, Россия Федерациясе субъекты, муниципаль берәмлекләр өлеше булу | | |
| 2. | Кредит оешмасының Татарстан Республикасында терри-ториаль структур бүлекчәсе булу | | |
| 3. | Кредит оешмасының халыкара агентлыкларның берсе тарафыннан билгеләнгән һәм бирелгән финанс рейтингы булу (Moody’s Investors Service, яки Standard & Poor’s, яки Fitch Ratings) | | |
| 4. | Банкның үз акчасы күләме (сайлап алуда катнашу өчен заявка тапшыру көненә кадәр булган соңгы хисап датасына) | | |
| 5. | Счетларны ачу бәясе | | |
| 6. | Онлайн-программалар кулланып, счетларга хезмәт күрсәтү бәясе | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| 7. | Счетларга хезмәт күрсәтү бәясе | | |
| 8. | Барлык счетлардагы уртача айлык калган акчаның гомуми суммасын исәпкә алып, төбәк операторы идарәсендәге счетларда булган уртача айлык калган акчага процентларны күчерү һәм түләү мөмкинлеге булу | | |
| 9. | «Дистанцион банк хезмәте күрсәтү» системасында «Түләүләрнең күп баскычлы акцепты» хезмәте булу | | |
| 10. | Электрон элемтә каналлары буенча клиентка үзенең счетлары белән оператив идарә итү мөмкинлеге белән, әлеге счетлар, шулай ук аның структур бүлекчәләре счетлары торышы турында оператив рәвештә мәгълүмат алырга мөмкинлек бирә торган сервис булу | | |
| 11. | Клиентка, берничә баскычны куллану һәм параметрларны оператив үзгәртү мөмкинлеге белән, планлаштырылган чыгым операцияләре буенча бюджет контролен һәм үтәлешен гамәлгә ашырырга мөмкинлек бирә торган сервис булу | | |
| 12. | «Банк-клиент» системасыннан файдаланмыйча, төбәк операторының исәпкә алу системасы һәм банк арасында автоматик мәгълүмат алышу мөмкинлеге булу | | |

2. Әлеге заявка белән шулай ук ________________________________________________
__________________________________________________________________________ карата
*(кредит оешмасы иseме)*
ябу, банкротлык (акчасызлык) процедуралары алып барылмавын, эшчәнлеге туктатылмавын раслыйбыз.

3. Әлеге заявка белән ___________________________________________________________
__________________________________________________________________________ карата
*(кредит оешмасы исеме)*
аерым банк операцияләре кылуга һәм филиаллар ачуга тыюлар формасында, шулай ук аерым банк операцияләрен гамәлгә ашыруга лицензияләрнең гамәлдә булуын туктатып тору рәвешендә Россия Федерациясе Үзәк банкы санкцияләре булмавын, Россия Федерациясе Үзәк банкының үтәлмәгән күрсәтмәләре булмавын раслыйбыз.

4. Әлеге заявка белән без заявкада китерелгән мәгълүматларның дөреслеген гарантиялибез һәм конкурс нигезендә сайлап алуны оештыручыларның без керткән белешмәләрне тәгаенли торган теләсә нинди мәгълүмат соратып алу хокукын раслыйбыз.

5. Конкурс тәкъдимнәребез иң яхшы дип танылган очракта, төбәк операторыннан шартнамә проектын алган көннән соң 10 (ун) эш көне эчендә конкурс документлары таләпләре һәм безнең конкурс тәкъдиме шартлары нигезендә төбәк операторы белән банк счеты шартнамәсен төзү йөкләмәсен үз өстебезгә алабыз.

6. Әлеге заявка конкурс нигезендә сайлап алу процедурасы тәмамланганчы гамәлдә була.

Кушымталар:

1. Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан билгеләнгән сайлап алуда катнашу өчен заявка тапшыру көненә кадәр булган соңгы хисап датасына кредит оешмаларының үз акчасын (капиталын) билгеләү методикасы нигезендә исәпләнгән кредит оешмасының үз акчасы (капиталы) күләме турында Россия кредит оешмасының вәкаләтле заты тарафыннан имзаланган белешмә;

Россия Федерациясе Үзәк банкы тарафыннан бирелгән банк операцияләрен гамәлгә ашыруга лицензиянең нотариаль рәвештә таныкланган күчермәсе.

2. Россия кредит оешмасында төбәк операторы счеты һәм махсус счетлар ачкан очракта, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибенең 3.1 пунктында күрсәтелгән таләпләргә кредит оешмасының туры килмәү фактлары барлыкка килү турында, алар барлыкка килгән вакыттан 3 эш көненнән дә соңга калмыйча, төбәк операторына хәбәр итү буенча язмача йөкләмә.

3. Фирма исемен, оештыру-хокукый формасы, урнашкан урыны, почта адресы турындагы мәгълүматларны үз эченә алган дәгъвачы хакында белешмәләр һәм документлар;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар (кредит оешмасының ихтыяры буенча бирелә) бирелмәгән очракта, төбәк операторы тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 2 пункты нигезендә соратып алына;

соңгы хисап датасына исәпләнгән салымнар, җыемнар һәм һәртөрле дәрәҗәдәге бюджетларга яки дәүләт бюджеттан тыш фондларга бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмау турында белешмә (кредит оешмасының ихтыяры буенча бирелә) бирелмәгән очракта, төбәк операторы тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек тәртибендә «Дәүләт хезмәтләре һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешнең 2 пункты нигезендә соратып алына.

4. Дәгъвачы исеменнән гамәлләр кылуга затның вәкаләтләрен раслый торган документ.

Кредит оешмасының реквизитлары:
ОГРН ______________________________________
ИНН/КПП ________________________________
Урнашкан урыны: ___________________________
Почта адресы: ______________________________
к/с _________________________________________
БИК _________________________________________
_________________/ __________________________
*(имза)* *(Ф.И.Ат.и.)*

Әлеге заявкага кушымта ________ биттә.

*(Кушымта документлар аерым исемлектә күрсәтелә.)*

Кредит оешмасы җитәкчесе _________________/ _____________________________
*(имза)* *(Ф.И.Ат.и.)*

Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибенә 3 нче кушымта

Форма

«Раслыйм»

________________________________________
*(төбәк операторы җитәкчесе имзасы, Ф.И.Ат.и.)*

Конкурсның 20___ел, «__» ____________, ______ беркетмәсе

______________________________________________________________________________________________________
*(конкурс исеме)*

______________________________________________________________________________________________________
*(бәяләү һәм заявкаларны чагыштыруны үткәрү урыны, дата)*

Конкурс комиссиясе составы:

Конкурс комиссиясе рәисе _______________________________________________________________.
*(Ф.И.Ат.и., вазыйфасы)*

Конкурс комиссиясе секретаре _____________________________________________________________.
*(Ф.И. Ат.и., вазыйфасы)*

Конкурс комиссиясе әгъзалары _____________________________________________________________
*(Ф.И. Ат.и., вазыйфасы)*

______________________________________________________________________________________________________
_____________________________________________________________________________________________________.

Конкурс заявкаларын бәяләү һәм чагыштыру процедурасына түбәндәге конкурста катнашучыларның заявкалары кертелде:

______________________________________________________________________________________________________
*(конкурста катнашучы исеме, адресы)*

______________________________________________________________________________________________________

Заявкаларны һәм конкурс тәкъдимнәрен бәяләүне конкурс комиссиясе Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибенә 1 нче кушымтада билгеләнгән критерийлар буенча үткәрде.

«Тотрыклылык дәрәҗәсе», «Ышанычлылык дәрәҗәсе», «Хезмәт күрсәтү бәясе» һәм «Акча чыгымнарын контрольдә тоту һәм аларның куркынычсызлык дәрәҗәсе» критерийлары буенча заявкаларны бәяләү нәтиҗәләре әлеге беркетмәгә теркәлгән кушымтада чагылды.

Конкурс комиссиясе заявкаларны бәяләү нәтиҗәләрен чыгарды.

Заявкаларны һәм конкурс тәкъдимнәрен бәяләү һәм чагыштыру нәтиҗәләре буенча кертелгән заявкаларга түбәндәге урыннар бирелде:

1. _______________________________________________________________,
2. __________________________________________________________ һ.б.

Конкурста җиңүче дип _____________________________________________________________ танылды.
*(оешма исеме)*

Конкурс комиссиясе рәисе __________/ ______________________
*(имза) (Ф.И. Ат.и.)*

Конкурс комиссиясе әгъзалары __________/ ___________________
*(имза) (Ф.И. Ат.и.)*

__________/ ___________________
*(имза) (Ф.И. Ат.и.)*

__________/ ___________________
*(имза) (Ф.И. Ат.и.)*

Конкурс беркетмәсенә кушымта

| Т/с | Катнашучы исеме | Заявканы теркәү көне һәм вакыты | Заявканы ачу һәм карап тикшерү көне | «Тотрыклылык дәрәҗәсе» критерие | | | | | | | «Ышанычлылык дәрәҗәсе» критерие | | «Хезмәт күрсәтү бәясе» критерие | | | | | | | «Акча чыгымнарын контрольдә тоту һәм аларның куркынычсызлык дәрәҗәсе» критерие | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | ярдәмче критерийлар | | | | | | балл | | | ярдәмче критерийлар | | | | | | балл | ярдәмче критерийлар | | | | | | балл |
| | | | | зурлыгы | балл | булу-булмау | балл | булу-булмау | балл | | зурлыгы | балл | бәясе | балл | бәясе | балл | % | балл | | булу-булмау | балл | булу-булмау | балл | булу-булмау | балл | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |
| | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | | |

Конкурс комиссиясе рәисе ________________/ _________________________
*(имза)* *(Ф.И. Ат.и.)*

Конкурс комиссиясе әгъзалары ________________/ _________________________
*(имза)* *(Ф.И. Ат.и.)*

________________/ _________________________
*(имза)* *(Ф.И. Ат.и.)*

________________/ _________________________
*(имза)* *(Ф.И. Ат.и.)*

________________/ _________________________
*(имза)* *(Ф.И. Ат.и.)*

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2016 ел, 21 гыйнвар, 28 нче
карары белән расланды

# Төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү тәртибе

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда, Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтү фондларын формалаштыру максатларында, күпфатирлы йорттагы бүлмәләрнең милекчеләре махсус счет ачылачак кредит оешмасын сайламаган яки бу кредит оешмасы Россия Федерациясе Торак кодексының 170 статьясындагы 4 өлешнең 5 пунктында һәм 176 статьясындагы 2 өлештә күрсәтелгән таләпләргә туры килмәгән очракта төбәк операторы тарафыннан счет һәм махсус счетлар ачу өчен Россия кредит оешмаларын сайлап алу буенча конкурс үткәрү процедурасын һәм конкурс шартларын билгели.

1.2. Ачыклык, билгелелек, ярышучанлык һәм конкурсның барлык дәгъвачылары һәм катнашучылары өчен тигез шартлар конкурсны оештыру һәм үткәрүнең төп принциплары булып тора.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә түбәндәге төшенчәләр кулланыла:

вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрлыгы;

төбәк операторы – күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь төзәтү үткәрүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне гамәлгә ашыручы «Татарстан Республикасының торак-коммуналь хуҗалык фонды» коммерциягә карамаган оешмасы;

конкурс комиссиясе – вәкаләтле орган оештырган коллегиаль орган;

дәгъвачы – әлеге Тәртип нигезендә конкурста катнашуга заявка биргән Россия кредит оешмасы;

конкурста катнашучы – конкурс комиссиясе тарафыннан конкурста катнашу рөхсәт ителгән дәгъвачы;

конкурста җиңүче – Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлештә билгеләнгән таләпләргә туры килүче һәм төбәк операторы счетын һәм махсус счетларны ачу һәм алып бару өчен иң уңайлы шартлар тәкъдим иткән конкурста катнашучы;

конкурс документлары – заявканы әзерләү һәм формалаштыру кагыйдәләрен, конкурста катнашучыларга һәм дәгъвачыга конкурста катнашуга рөхсәт бирү өчен кирәкле документлар составына таләпләрне үз эчендә алган документлар комплекты;

конкурста катнашуга заявка (алга таба – заявка) – дәгъвачы тәкъдимнәрен үз эченә алган һәм конкурс документларына ярашлы формада һәм тәртиптә төбәк операторына җибәрелгән документ;

шартнамә – Россия Федерациясе Торак кодексында каралган очракларда төбәк операторы счетын һәм хуҗасы төбәк операторы булган махсус счетларны ачу турында шартнамә.

2. Вәкаләтле орган, төбәк операторы һәм конкурс комиссиясе вазыйфалары

2.1. Конкурс үткәрү турында карарны вәкаләтле орган кабул итә.

2.2. Вәкаләтле орган әлеге Тәртипнең 2.1 пункты нигезендә кабул ителгән карар турында кабул ителгән көненнән соң бер эш көне эчендә төбәк операторына язма рәвештә хәбәр итә.

2.3. Вәкаләтле орган:

конкурс комиссиясен оештыра, конкурс комиссиясе һәм аның составы турында нигезләмәне раслый;

конкурс документларын раслый.

2.4. Төбәк операторы:

конкурс документларын эшли, конкурс үткәрү, аның шартлары үзгәрү турында, үткәрелгән конкурс йомгаклары хакында белдерү әзерләүне һәм бастырып чыгаруны оештыра;

дәгъвачылардан заявкалар кабул итә, заявкалар кабул итү журналын алып бара;

конкурс үткәрүне оештыра;

конкурс нәтиҗәләре турында беркетмәне раслый;

конкурс нәтиҗәләре буенча шартнамә төзи.

2.5. Конкурс комиссиясе:

дәгъвачыларга конкурста катнашырга рөхсәт итү (яисә рөхсәт итмәү) турында карар кабул итә;

конкурс нәтиҗәләре турында беркетмәне рәсмиләштерә;

заявкаларны карап тикшерә һәм конкурста җиңүчене билгели.

3. Конкурста катнашучыларга таләпләр һәм бәяләү критерийлары

3.1. Конкурста катнашу түбәндәге таләпләргә туры килә торган Россия кредит оешмаларына рөхсәт ителә:

Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлеш нигезендә үз акчасы (капиталы) 20 млрд. сумнан ким булмаган;

банк операцияләрен гамәлгә ашырырга Россия Федерациясе Үзәк банкы биргән лицензиясе булган;

соңгы хисап датасына салымнар, җыемнар һәм һәртөрле дәрәҗәдәге бюджетларга яки дәүләт бюджеттан тыш фондларга бүтән мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаган.

3.2. Конкурс комиссиясе конкурста катнашучыларның заявкаларын һәм конкурс тәкъдимнәрен түбәндәге критерийлар буенча бәяләүне гамәлгә ашыра:

тотрыклылык дәрәҗәсе: балларның максималь саны – 36;
ышанычлылык дәрәҗәсе: балларның максималь саны – 12;
хезмәт күрсәтү бәясе: балларның максималь саны – 22;
акча чыгымнарын контрольдә тоту һәм аларның куркынычсызлык дәрәҗәсе – балларның максималь саны – 30.

3.3. Дүрт критерий буенча балларның гомуми максималь саны – 100.

3.4. Заявкаларны һәм конкурс тәкъдимнәрен бәяләү, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымтаның 1 – 4 таблицалары нигезендә «тотрыклылык дәрәҗәсе», «ышанычлылык дәрәҗәсе», «хезмәт күрсәтү бәясе», «акча чыгымнарын контрольдә тоту һәм аларның куркынычсызлык дәрәҗәсе» критерийлары буенча заявкаларга конкурс комиссиясе тарафыннан эзлекле рәвештә баллар санын куеп, башкарыла.

3.5. Һәр ярдәмче критерий буенча баллны билгеләгәннән соң, баллар һәр катнашучы өчен кушыла. Аннары баллар һәр катнашучы өчен бәяләү критерийлары буенча кушыла.

3.6. Иң күп санда балл җыйган конкурста катнашучы конкурста җиңүче дип таныла. Күрсәткечләрнең тигезлеге очрагында урыннар заявканы теркәү датасы һәм вакыты буенча бүленә.

## 4. Конкурсны үткәрү турында белдерү

4.1. Конкурсны үткәрү датасына кимендә 20 календарь көн алдан төбәк операторы «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында конкурсны үткәрү һәм конкурс документлары турында белдерү бастырып чыгара.

4.2. Конкурсны үткәрү турында белдерү түбәндәге мәҗбүри мәгълүматларны үз эченә алырга тиеш:

а) конкурсның предметы;
б) конкурста катнашуга заявкалар кабул итү башлану һәм тәмамлану вакыты;
в) конвертларны ачу урыны, датасы һәм вакыты;
г) заявкаларны карап тикшерү һәм бәяләү датасы;
д) төбәк операторының элемтә телефоны номеры һәм урнашу урыны, төбәк операторының җаваплы вазыйфаи затының Ф.И.Ат.и.;
е) беркетмәгә имза кую һәм аны бастырып чыгару вакыты;
ж) конкурста җиңүче белән шартнамәне имзалау вакыты.

## 5. Заявкалар тапшыру һәм кабул итү

5.1. Дәгъвачы әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча язмача заявканы конкурсны үткәрү турында белдерүдә күрсәтелгән заявкаларны кабул итү тәмамлану датасыннан соңга калмыйча төбәк операторына тапшыра. Заявка кәгазьдә формалаштырыла, вәкаләтле затлар имзасы һәм, мөһер булганда, дәгъвачы мөһере белән таныклана һәм ябыштырылган конвертта тапшырыла.

5.2. Заявкага әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтада күрсәтелгән документлар теркәлә.

5.3. Төбәк операторы белдерүдә күрсәтелгән вакытларда заявкаларны кабул итүне гамәлгә ашыра. Бу чакта әлеге Тәртипнең 4.1 пункты нигезендә белдерү бастырып чыгарылган көннән соң килә торган көн заявка тапшыру вакыты башлану датасы булып тора.

5.4. Заявка аны тапшырган көннән соң бер эш көне эчендә төбәк операторы тарафыннан, аны тапшырган датаны һәм төгәл вакытын күрсәтеп, заявкаларны кабул итү журналына теркәлә.

5.5. Белдерүдә күрсәтелгән кабул итү вакыты башланганчы яки үткәннән соң кергән заявкалар карап тикшерүгә кабул ителми һәм аларны теркәгән көннән соң биш эш көне эчендә ачылмаган рәвештә дәгъвачыларга (аларның вәкаләтле вәкилләренә) кире кайтарыла.

5.6. Дәгъвачы конвертларны ачу датасына кадәр бер эш көненнән дә соңга калмыйча тапшырылган заявканы кайтарып алырга хокуклы. Заявканы кайтарып алу турында белдерү дәгъвачы тарафыннан язма рәвештә заявка алып барып җиткерелгән адрес буенча бирелә. Заявканы кайтарып алу турында белдерү катнашучы оешма тарафыннан имзаланган һәм аның мөһере белән таныкланган булырга тиеш (Россия Федерациясе законнарында мөһергә ия булу йөкләмәсе билгеләнгән очракларда). Кайтарып алынган заявка, теркәлгән документлары белән бергә, конкурсны оештыручылар тарафыннан дәгъвачыга кире кайтарыла.

Заявканы кайтарып алу дәгъвачы тарафыннан заявканы кайтарып алу турында белдерү тапшырылган көннән соң бер эш көне эчендә заявкаларны кабул итү журналына теркәлә.

5.7. Заявкалар кабул итү вакыты тәмамланганнан соң төбәк операторы заявкаларын кабул итү вакыты тәмамланган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча дәгъвачыларны конкурста катнашучылар дип тану турында карар кабул итү өчен кергән заявкаларны конкурс комиссиясенә тапшыра.

## 6. Конкурсны үткәрү процедурасы

6.1. Конкурс комиссиясе Россия кредит оешмаларының заявкалары белән конвертларны ача, заявкаларын карап тикшерә һәм аларны төбәк операторыннан алган көннән соң бер эш көненнән дә соңга калмыйча үзенең утырышында конкурста җиңүчене билгели.

6.2. Ябыштырылган конвертларны ачар алдыннан конкурс комиссиясе аларның бөтенлеген тикшерә.

6.3. Конкурс комиссиясе кергән заявкаларны игълан итә, заявкага теркәлгән документларны тикшерү үткәрә, дәгъвачыга конкурста катнашырга рөхсәт итү яки әлеге Тәртипнең 6.1 пунктында күрсәтелгән утырышта катнашырга рөхсәт итмәү турында карар кабул итә.

6.4. Дәгъвачыга конкурста катнашырга рөхсәт итмәү өчен түбәндәгеләр нигез була:

дәгъвачының әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында күздә тотылган таләпләргә туры килмәве;

әлеге Тәртипнең 5.2 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырмау.

6.5. Конвертларны ачканда һәм тәкъдимнәрне яңгыратканда тәкъдиме карап тикшерелә торган катнашучыдан тыш конкурсның башка катнашучылары яки аларның ышанычнамәләре булган вәкаләтле вәкилләре катнаша ала.

6.6. Конкурс тәкъдимнәрен бәяләгәндә һәм чагыштырганда конкурста катнашучылар катнашмый.

6.7. Конкурста катнашучыларның тәкъдимнәрен бәяләү конкурсны үткәргәндә катнашкан конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан, әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә критерийлар буенча балларда башкарыла.

6.8. Конкурста җиңүче дип Россия Федерациясе Торак кодексының 176 статьясындагы 2 өлештә билгеләнгән таләпләргә туры килүче, тәкъдиме конкурсның барлык шартларына җавап биргән һәм әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә конкурс критерийларының билгеләнгән параметрлары буенча максималь санда баллар җыйган катнашучы танылa.

Тәкъдимнәр тигезлеге очрагында заявкасы иртәрәк тапшырылган конкурста катнашучы җиңүче дип танылa.

6.9. Конкурс түбәндәге очракларда булмаган дип санала:

әгәр конкурс үткәрү турында белдерүдә күздә тотылган заявкалар тапшыру тәмамлану вакытына конкурста катнашуга бер генә заявка да кермәсә;

әгәр заявкаларны карап тикшерү нәтиҗәләре буенча барлык дәгъвачыларга конкурста катнашу рөхсәт ителмәсә;

әгәр конкурста катнашу бер генә заявкага рөхсәт ителсә, бу чакта шартнамә бердәнбер катнашучы белән төзелә, аның әлеге Тәртипнең 3.1 пунктында каралган таләпләргә туры килүе шартларында.

## 7. Конкурс нәтиҗәләрен рәсмиләштерү һәм шартнамә төзү

7.1. Конкурс нәтиҗәләре үткәрелгән көненнән соң өч эш көне эчендә әлеге Тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә форма буенча конкурс беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңарга конкурс комиссиясе әгъзалары имза куя, төбәк операторы раслый. Беркетмә датасы булып аңарга имза куелган көн санала.

Конкурс беркетмәсе ике данәдә төзелә, аның берсе имза куелган көннән соң бер эш көне эчендә шартнамә проекты белән бергә конкурста җиңүчегә җибәрелә, икенчесе төбәк операторында кала.

7.2. Конкурс беркетмәсендә күрсәтелә:

а) конкурсның исеме;

б) заявкаларны бәяләүне һәм чагыштыруны үткәрү урыны, датасы;

в) конкурс комиссиясе составы;

г) конкурста катнашучылар исеме, адреслары;

д) заявкаларны һәм конкурс тәкъдимнәрен бәяләү һәм чагыштыру нәтиҗәләре;

е) конкурста җиңүче.

7.3. Конкурс нәтиҗәләре турында беркетмә, аңарга имза куелган көннән соң ике эш көне эчендә «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә төбәк операторының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш.

7.4. Шартнамә конкурс документларында каралган шартларда һәм тапшырылган конкурс тәкъдимнәре нигезендә төзелә.

7.5. Төбәк операторы үзе имза куйган шартнамә проектын адресатына тапшыру турында белдерү белән заказлы хатта почта аша конкурста җиңүчегә җибәрә.

Әгәр расланган шартнамә проекты конкурста җиңүчегә тапшырылса, җиңүче тарафыннан шартнамә проектын алуны раслау шартнамәләрне теркәү журналына теркәлә.

7.6. Әгәр конкурста җиңүче төбәк операторыннан шартнамә проектын алган көннән соң 10 эш көне эчендә аңарга үзе имза куйган шартнамәне тапшырмаса, ул шартнамә төзүдән качарга тырышкан дип санала һәм төбәк операторы заявкасы конкурста җиңүчедән кала иң күп балл җыйган конкурста катнашучы белән шартнамә төзи, моның өчен әлеге пунктта күрсәтелгән вакыт узган көннән соң өч эш көне эчендә әлеге Нигезләмәнең 7.5 пунктында билгеләнгән тәртиптә үзе ягыннан расланган шартнамә проектын җибәрә.

7.7. Әгәр заявкасы конкурста җиңүчедән кала иң күп балл җыйган конкурста катнашучы яисә конкурсның бердәнбер катнашучысы төбәк операторыннан шартнамә проектын алган көннән соң 10 эш көне эчендә аңарга үзе имза куйган шартнамәне тапшырмаса, вәкаләтле орган карары нигезендә һәм әлеге Тәртипкә яраклы рәвештә кабат конкурс үткәрү оештырыла.

7.8. Конкурс комиссиясе, вәкаләтле орган, төбәк операторы карарларына һәм гамәлләренә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелә ала.